МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.01.2023 г. Казань № под-129/23

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр күләмен билгеләү тәртибен һәм аларны бирү шартларын билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октяберендэ 764 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр билгеләү тәртибен һәм аларны бирү шартларын билгеләүгә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары карары нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын 2022 елда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Балаларга өстәмә белем бирү бүлегенә (А.Р.Кашапова) әлеге боерыкка Россия Федерациясе законнары билгеләгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт регистрациясен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының урынбасары А.М.Асадуллинага йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2023 елның «27» январьдегә <u>под-129/23</u> номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һэм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын 2022 елда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һэм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын 2022 елда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

Чара – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10

октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору»;

Гамәлгә куючы – Учреждениегә карата гамлгә әкую функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

субсидия – Учреждениегә Гамәлгә куючы булып Татарстан Республикасы бюджеты турндагы закон нигезендә, бюджет акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына Учреждениегә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты хисабына Дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелә торган субсидия.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

3. Учреждениегә субсидия чараларын гамәлгә ашыру максатларында бирелә:

организация курсов повышения квалификации, различные научно-практические мероприятия для специалистов, работающих в области профилактики правонарушений, с привлечением ученых, практиков, представителей органов власти, сотрудников правоохранительных органов.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия алу максатында Учреждение Гамәлгә куючы адресына документлар исемлеген тапшыра, ул түбәндәгеләрдән тора:

Учреждениенең субсидия алуга ирекле рәвештә рәсмиләштерелгән язмача мөрәҗәгате;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга бюджет акчаларын бирү зарурлыгын нигезләгән аңлатма язуы, Субсидия суммасының исәпләмә-нигезләүне, шул исәптән Программаны гамәлгә ашыру өчен беренчел сметаны да кертеп, ул аларның күләмнәрен нигезли торган мәгълүматны күрсәтеп, чыгымнарның планлаштырылган юнәлешләре буенча калькуляцияне үз эченә ала (счетлар, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең коммерция тәкъдимнәре, җитештерүче оешмаларның бәяләре, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп);

Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче көненә булган торышында салым түләүче (җыем түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча йөкләмәләр үтәлүе турында салым органы белешмәсе;

Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче көненә булган торышында Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычларның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрнең, бюджет инвестицияләренең булмавы турында Учреждение җитәкчесе һәм баш хисапчы, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган, Учреждение мөһере (булган очракта)

белән беркетелгән белешмә, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында, җирле хакимиятнең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш;

Тапшырылган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Документларның күчермәләре Учреждениенең мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм моңа вәкаләт бирелгән затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән таныкланган булырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән расланган булырга тиеш.

5. Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге алынганнан соң 10 эш көне эчендә аларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм Учреждениегә Субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Учреждениегә Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

6. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә Гамәлгә куючы һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәк нигезендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи, анда түбәндәге нигезләмәләр була:

Субсидияне бирү максатлары, Программаның исемен күрсәтеп;

Субсидия бирү нәтиҗәләренең әһәмияте, алар конкрет, үлчәмле булырга һәм Программа нәтиҗәләренә туры килергә тиеш;

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

Субсидиянең күләме;

Субсидияне күчерү вакыты (графигы); хисаплылык тапшыру чорлары;

Учреждение килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, Субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Гамәлгә куючыга Субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;

Гамәлгә куючы карары буенча килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату нигезләре, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:

Учреждениене үзгәртеп кору (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерүгә бәйле рәвештә;

Учреждение тарафыннан хокукый актта һәм (яки) килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү максатлары һәм шартлары бозылган очракта;

Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә.

Кирәк булуга карап, Гамәлгә куючы һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәкләр нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

7. Субсидиянең күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum_{i=1}^{5} З_i,$$

биредә:

$З_1$ – хезмәт законнары нигезендә Учреждениенең Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$З_2$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр кысаларында транспорт чараларын яңадан җиһазландыру эшләрен оештыру һәм үткәрү чыгымнары;

$З_3$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр буенча барлык төр транспорт чараларына техник экспертиза оештыру һәм үткәрү чыгымнары;

$З_4$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр буенча укыту курслары һәм тренинглар оештыру һәм үткәрү чыгымнары;

$З_5$ – ягулык-майлау материаллары чыгымнары буларак билгеләнә торган транспорт чыгымнары;

$З_6$ – Учреждениенең Программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләренең командировка чыгымнары;

$З_7$ – матди запасларны арттыру чыгымнары (тарату, укыту-методик, чыгым материалы, оештыру техникасы сатып алу), алар чагыштырма базар бәяләре методы (базарны анализлау) нигезендә билгеләнә, ул бердәй (бер төрле) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән оештыручы-әзерләүчеләрнең бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт.

$З_8$ – Россия Федерациясе Салымнар һәм җыемнар турындагы законнар белән билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яисә) бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү чыгымнары.

8. Субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырыла торган айның беренче көненә Учреждение туры килергә тиешле таләпләр:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычлары, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләре, бюджет инвестицияләре юк, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару өчен субсидия бирелгән, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында, җирле хакимиятнең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш;

Учреждение әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка актлары нигезендә акча алмый.

9. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып Учреждениенең әлеге Тәртипкә беренче кушымтада билгеләнгән Дәүләт программасы чаралары нәтиҗәләренә (ахыргы нәтиҗәне бәяләү индикаторларына) ирешүе тора.

10. Гамәлгә куючы субсидияне Учреждениенең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап счетларына килешүдә каралган Субсидияне күчерү графигы нигезендә тулы күләмдә күчерә.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

11. Учреждение Гамәлгә куючыга хисаплылыкны түбәндәге срокларда тапшыра:

квартал саен, хисаплылык тапшырыла торган кварталдан өч эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге үрнәк буенча финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, хакыйкый тотылган чыгымнарны раслый торган, таныкланган документларны теркәп, чыгымнар тоту турында хисаплылык;

ай саен, хисаплылык тапшырыла торган айдан өч эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендәге үрнәк буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык;

хисаплылык тапшырыла торган елның соңгы аеның 25 еннән соңга калмыйча, килешүне үтәү турында Гамәлгә куючы раслый торган формадагы хисаплылык;

квартал саен, хисаплылык тапшырыла торган кварталдан өч эш көненнән соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендәге үрнәк буенча чаралар планын үтәү турында хисаплылык.

Тапшырыла торган хисаплылык аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

## IV. Субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольлекне һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

12. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы Учреждениегә субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен зарури контрольдә тота.

13. Учреждение субсидия алу өчен яки субсидиядән файдалану турында дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган, чаралар планын, субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган, шулай ук субсидияне тоту максатларын бозган, әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән хисаплылык тапшырмаган өчен җаваплы була.

Учреждениене җаваплылык чараларын кулланудан азат итү өчен нигез булып Учреждение тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә комачаулый торган, җиңеп булмаслык шартларның барлыкка килүе турында документаль раслама тора.

14. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә Учреждениенең субсидия бирү вакытында билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, субсидия Гамәлгә куючының тиешле таләбе Учреждение тарафыннан алынганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең беренче кушымтасында билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешмәгән очракта, субсидия Гамәлгә куючының тиешле таләбе алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләп чыгарыла торган 30 көнлек чорда, Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

15. Учреждение субсидиянең әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән кайтару срогын үтәмәгәндә, Гамәлгә куючы җиде эш көне эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

16. Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып агымдагы финанс елының 1 гыйнварына тотылмаган субсидиянең калган өлеше булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләр булуы турындагы, субсидия бирү елыннан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате), шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен

әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карарны Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате алынган датадан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

17. Гамәлгә куючының агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карары нигезендә субсидиянең калган өлеше әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатларга юнәлдерелгән чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен агымдагы елда файдаланылырга мөмкин.

18. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен элегрәк түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча күчкән очракта, Гамәлгә куючы Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кайтарудан алынган акчалар торган үтәмәгән йөкләмәләр (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында субсидия бирелгән елдан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба - Учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгате), шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен Учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан күчкән акчаларны агымдагы финанс елында файдалану турындагы карарны Учреждение элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгать иткән датадан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта

Дәүләт программасы чаралары нәтиҗәләре
(ахыргы нәтиҗәне бәяләү индикаторлары)

| п/п | Нәтиҗә (ахыргы нәтиҗәне бәяләү индикаторы) атамасы, үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә (ахыргы нәтиҗәне бәяләү индикаторы) кыйммәте |
|---|---|---|
| | | 2023 |
| 1. | Эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләрендә исәптә торучы балигъ булмаганнар, кеше саны | 2800 |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык
20___елның «___» ________на

Учреждениенең исеме __________________________________________
Периодиклык: квартал саен
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесенә кадәр төгәллек белән)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | хисап чоры өчен | ел башыннан үсә баручы нәтиҗәсендә |
| *1* | *2* | *3* |

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчалары<br>күчте | | |
| Субсидия акчалары тотылды (касса чыгымнары) | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылды | | |
| Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше | | |
| Шул исәптән:<br>кайтарып бирелергә тиешле | | |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

Субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
20___елның “___”_________на

Учреждениенең исеме ____________________________________________
Периодиклык: ай саен

| Т/с | Күрсәткеч атамасы | елга план күрсәткече | Хисап датасына ирешелгән күрсәткеч | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гамәлгә куючысы Учреждение

/ФИА / /ФИА /

Мөһер урыны Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәгән «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ярдәмче программасының 1.5 пункты буенча «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 10 октябрендә 764 номерлы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дүләт программасы чараларын 2022 елда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

Субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен план чараларын тормышка ашыру турында хисаплылык
20____елның “_____”_____на

| | | | КОДЛАР |
|---|---|---|---|
| | | Дата | |
| | | Бердәм реестр буенча | |
| Кабул итүче атамасы | ____________________ | ИНН | |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгымнарны төп таратучының атамасы | ____________________ (Министрлык) | Бердәм реестр буенча | |
| Дәүләт программасының структур элементының атамасы | ____________________ | БК буенча | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Субсидия атамасы | ____________________ | БК буенча | |
| | ____________________ | Килешү номеры | |
| | | Килешү датасы | |
| Документ төре | ____________________ (беренчел – «0», төгәлләнгән – «1», «2», «3», «...») | | |

| Субсидия бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Кыйммәте | | | Ирешү срогы (кк.аа.ееее.) | | Статусы | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атама | код | төр | атама | ОКЕИ буенча код | план | факт | прогноз | план | факт | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль пунктлары | х | | | | | | | | | | |
| шул хисаптан: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| план чорының контроль пунктлары | х | | | | | | | | | | |
| шул хисаптан: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Учреждение җитәкчесе (вәкаләтле зат) ____________ ____________ ____________

(вазыйфа) (имза) (ФИА)

Башкаручы ____________ ____________ ____________

(вазыйфа) (АИФ) (телефон)

«__» _________ 20__ел